| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2024 г.Казань № 693-188/кс-2024

2025 елга Лениногорск муниципаль районының «ТаграС-ЭнергоСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 19.12.2024 ел, №36-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган Лениногорск муниципаль районының «ТаграС-ЭнергоСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ТаграС-ЭнергоСервис» ЖЧЖ) тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга Федераль тарифлар хезмәтенең 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 114.1 пункты нигезендә билгеләнә торган формула рәвешендә билгеләргә:

$$Т^{гвс}_{закр} = Т_{хвс} + Т^{тэ}_{i} * Q^{т/э}$$

биредә: $Т_{хвс}$– Лениногорск муниципаль районының «Водоканал» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2025 елга эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2024 ел, №601-155/кс-2024 карары белән билгеләнгән тариф;

$Т_i^{тэ}$ – җылылык энергиясенә (егәрлегенә) компонент яклар килешүе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую нигезләренең 5(5) пункты нигезендә билгеләнә торган тариф;

$Q^{т/э}$ – салкын суның бер кубик метрын җылыту өчен кирәкле, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының 16.11.2023 ел, №168/о боерыгы нигезендә билгеләнә торган җылылык энергиясе (егәрлек) күләме.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТаграС-ЭнергоСервис» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина